
# Әниләр көне!




Бу бәйрәм һәркайсыбыз өчен мөһим. Ул безнең иң газиз һәм кадерле кешеләребезгә – әниләребезгә багышланган. Безгә тормыш бүләк иткән, язмышның җил-давылларыннан саклап, йөрәк җылыларын биреп яратып-назлап үстергән, һәрчак безне кайгыртып, ярдәм итәргә әзер булып торган әниләребез алдында без мәңге бурычлы. Ана мәхәббәтеннән дә олырак хис юктыр. Ул безне көчлерәк итә, тормышта очраган төрле сынауларны җиңәргә булыша. Әниләр безгә гомер буе кирәк. Шатлыкта да, катлаулы авыр мизгелләрдә дә без аңа мөрәҗәгать итәбез.







Тубэн Элки авылы мэдэният йорты директоры Рэмзия Эсэдулла кызы шәхсән үз исеменнән Энилэр бэйрэме белэн котлады.

Нык сәламәтлек, ана бәхете, гаилә иминлеге телэде. Балаларыгыз һәрчак шатлык-сөенечләр генә китерсен, уңышлары белән куандырып торсын, сезгә игелек күрсәтсен. Бала хәсрәте күрергә язмасын. Өегездә тынычлык, бәхет, үзара аңлашу хөкем сөрсен.

Бәйрәм белән сезне!